КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № б-2950

Оешмаларның күчемсез мөлкәт объектларының кадастр кыйммәтеннән оешмалар мөлкәтенә салымны исәпләүгә күчү чараларын үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү, кадастр исәбен гамәлгә ашыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләү, дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү һәм күчемсез мөлкәт объектларына салым салу максатларында:

1. Оешмалар мөлкәтенә кадастр кыйммәтеннән салым исәпләүгә күчү чараларын үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү буенча ведомствоара эшче төркем составын төзергә.

2. Оешмалар мөлкәтенә кадастр кыйммәтеннән салым исәпләүгә күчү чараларын үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 декабрь, б-2950 нче
боерыгы белән расланды

# Оешмалар мөлкәтенә кадастр кыйммәтеннән салым исәпләүгә күчү чараларын үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Оешмалар мөлкәтенә кадастр кыйммәтеннән салым исәпләүгә күчү чараларын үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларның күчемсез мөлкәт объектларының кадастр кыйммәтеннән оешмалар мөлкәтенә салым исәпләүгә күчү нәтиҗәләрен бәяләү һәм законнарга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр эшләү, шулай ук кадастр исәбенә алуны гамәлгә ашыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләү, дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү һәм күчемсез мөлкәт объектларына салым салу чараларын гамәлгә ашыру максатларында төзелә.

1.2. 2. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Эшче төркемнәрнең бурычлары һәм функцияләре

2.1. Эшче төркемнең төп бурычы – Татарстан Республикасы территориясендә күчемсез мөлкәт объектларын кадастр исәбенә алуны гамәлгә ашыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләү, дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү һәм күчемсез мөлкәт объектларына салым салу.

2.2. Куелган бурыч нигезендә эшче төркем түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

күчемсез мөлкәт объектларын кадастр исәбенә алуны гамәлгә ашыруга, дәүләт кадастр бәяләвен үткәрүгә һәм күчемсез мөлкәт объектларына салым салуга бәйле мәсьәләләрне оператив карап тикшерү һәм хәл итү;

күчемсез мөлкәт объектларын кадастр исәбенә алу, дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү һәм күчемсез мөлкәт объектларына салым салу тармакларындагы мәсьәләләрне җайга салу буенча тәкъдимнәр әзерләү максаталрында мәгълүматны гомумиләштерү һәм анализлау;

оешмаларның күчемсез мөлкәт объектларының кадастр кыйммәтеннән оешмалар мөлкәтенә салым исәпләүгә күчү нәтиҗәләрен бәяләү.

## III. Эшче төркем составы

3.1. Эшче төркем эшче төркем җитәкчесе, эшче төркем җитәкчесе урынбасары, эшче төркем секретаре һәм әгъзалары составында формалаштырыла.

3.2. Эшче төркем составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән расланa.

Эш төркеме составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары вәкилләре (килешү буенча) һәм башка оешмалар вәкилләре (килешү буенча) керә.

3.3. Эшче төркем эшчәнлеге белән эшче төркем җитәкчесе җитәкчелек итә, ул:

эшче төркем утырышын үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгели;

эшче төркем утырышының көн тәртибен раслый;

эшче төркем утырышын алып бара;

эшче төркем утырышлары беркетмәләренә һәм карарларына имза куя;

эшче төркем тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

эшче төркем җитәкчесе урынбасары, эшче төркем секретаре һәм аның әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә.

3.4. Эшче төркем җитәкчесе урынбасары эшче төркем җитәкчесе кушуы буенча эшче төркем утырышларын үткәрә.

3.5. Эшче төркем әгъзалары:

эшче төркем утырышларында шәхсән үзләре катнаша;

эшче төркем утырышында катнашу мөмкинлеге булмаганда, эшче төркем утырышы башланганга кадәр бу турыда эшче төркем җитәкчесенә хәбәр итә;

эшче төркем җитәкчесенә эшче төркем утырышларында карап тикшерелергә тиешле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертә.

3.6. Эшче төркем секретаре:

эшче төркем әгъзаларының эшче төркем утырышында карап тикшерелергә тиешле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр гомумиләштерә, эшче төркем утырышының көн тәртибен формалаштыра һәм аны эшче төркем җитәкчесенә җибәрә;

эшче төркем утырышларына материаллар, шулай ук карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

эшче төркем әгъзаларына эшче төркем утырышының көн тәртибен таратып чыга;

эшче төркем әгъзаларын һәм чакырылган затларны барлык кирәкле белешмә-мәгълүмат бирү характерындагы материаллар белән тәэмин итә;

эшче төркем утырышы беркетмәсен алып бара.

## IV. Эшче төркем эшчәнлеге тәртибе

4.1. Эшче төркем эшчәнлеге эшче төркем утырышлары формасында гамәлгә ашырыла. Эшче төркем утырышы, әгәр анда эшче төркем әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Эшче төркем утырышлары эшче төркем тарафыннан карап тикшерелергә тиешле мәсьәләләр барлыкка килгәндә кирәк булуга карап үткәрелә. Эшче төркем утырышларын эшче төркем җитәкчесе, ә ул булмаганда яки аның кушуы буенча эшче төркем җитәкчесе урынбасары үткәрә.

4.2. Эшче төркем карарлары эшче төркем составына керүче һәм утырышта катнашучы затларның күпчелек тавышы белән кабул ителә, беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аларга эшче төркеме җитәкчесе яисә эшче төркем җитәкчесе урынбасары тарафыннан имза куела. Тавышлар тигез булганда, эшче төркем утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Эшче төркем утырышының имзаланган беркетмәсе һәм аның кушымталары күчермәләре, алга таба эшләү өчен, өч эш көне эчендә эшче төркем әгъзаларына электрон рәвештә җибәрелә.

___________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 декабрь, б-2950 нче
боерыгы белән расланды

Оешмалар мөлкәтенә кадастр кыйммәтеннән салым исәпләүгә күчү чараларын үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү буенча ведомствоара эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, эшче төркем җитәкчесе |
| Әһлиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры, эш төркеме җитәкчесе урынбасары |
| Рогожкин Максим Анатольевич | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары, эшче төркем секретаре |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Анфимова Алла Леонидовна | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары |
| Барышев Александр Георгиевич | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Борзунова Ксения Геннадьевна | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә караган дәүләт мөлкәте белән идарә итү бүлеге башлыгы |
| Галимов Айнур Газинур улы | Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары |
| Костин Артём Петрович | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Мерзакриев Рөстәм Рәүф улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Нәбиуллина Лилия Мөхәммәт кызы | Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Саматов Тимур Илгиз улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Сираҗиев Равил Раид улы | Татарстан Республикасы спорт министры урынбасары |
| Фролов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары |
| Хәмзина Лена Илдар кызы | «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры. |